Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«01» июль, 2022 ел № 28

Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 11 июленә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

- «Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру» сүзләрен

- «Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар алу һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга

Халык җыенын Иске Йорт авылының Үзәк урамы, 23 нче йорт адресындагы авыл клубы янәшәсендә үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Янсыбы авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- «Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру» сүзләрен

- «Су башняларын буяу өчен буяулар сатып алу, су башняларын буяу, су башняларын ремонтлау, артезиан скважиналары өчен насослар алу һәм урнаштыру» сүзләренә алмаштырырга
.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев